**СОВЕТ ТАТАРСКО - ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422634 с.Татар Янтык,
ул. Магазинная, д 31 а
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422634 Татарский Янтыгы авылы,
Кибет урамы, д 31а йорт
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**17 номер** **2019 елның 1 ноябре**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 19 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге- «2020 елда, яшәү урыны буенча, Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ яшьтәге һәр кешедән, бала чактан инвалид булганнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм,түбәндәге эшләрне башкару буенча, алынган акчаларны җирле мәсьәләләрне:

- Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пунктындагы урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтергә килешәсезме?"-дигән сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә, сайлау хокукына ия булган, 263 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 145 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында 145 катнашучы «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2«2020 елда, яшәү урыны буенча, Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ яшьтәге һәр кешедән, бала чактан инвалид булганнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм,түбәндәге эшләрне башкару буенча, алынган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Татар Янтыгы авыл җирлеге составына керүче Татар Янтыгы торак пунктын урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтергә килешәсезме?»- соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга

3. Әлеге карарны Татар Янтыгы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4 Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ________________ Р.М. Шамеев

Татар Янтыгы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ________________ Р.М. Шамеев

.

.

)